**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 25 май № 299

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы, 2016 ел, 7 октябрь, 720 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халык сәнгате һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты (алга таба – грант) – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү өчен кирәкле җиһазлар, кораллар һәм чыгым материаллар сатып алу өчен дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында бирелә торган субсидия;»;

1.5 пунктта:

«проектларны тормышка ашыруны максатчан финанслау өчен» сүзләреннән соң «, халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү өчен кирәкле җиһазлар, кораллар һәм чыгым материаллар сатып алу белән бәйле,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бу чакта халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү өчен кирәкле чыгым материалларын алуга грантның гомуми күләменең 10 проценттан артмаган өлеше тотыла ала.»;

2.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«проектны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми күләменең 15 проценттан ким булмаган өлешен үз акчасы исәбеннән финанслау буенча йөкләмә булу.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) юридик затны яисә физик затны законнарда билгеләнгән тәртиптә шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвенә алган моменттан соң кимендә бер ел халык сәнгате һөнәрләре өлкәсендә эш тәҗрибәсе.»;

6.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «к» и «л» пунктчаларын өстәргә:

«к) грантны куллану вакытын озайтуны тыю;

л) проектны тормышка ашырганда акча экономияләнгән очракта әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы дүртенче абзац нигезендә билгеләнгән грант алучының үз акчасы исәбеннән проектны финанслау күләмен исәпкә алып билгеләнгән күләмдә грант өлешен кире кайтару.»;

7.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Проектны тормышка ашырганда акча экономияләнгән очракта әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы дүртенче абзац нигезендә билгеләнгән грант алучының үз акчасы исәбеннән проектны финанслау күләмен исәпкә алып билгеләнгән күләмдә грант өлеше Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.»;

әлеге Тәртипкә 2 нче, 3 нче, 5 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәннәр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\299.docx